АССОЦИАЦИЯ
«СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНЫХ
ОБРАЗОВАНИЙ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН»

«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘРЕ
СОВЕТЫ»
АССОЦИАЦИЯСЕ

**РЕШЕНИЕ ПРЕЗИДИУМА** **ПРЕЗИДИУМ КАРАРЫ**

от 30.05.2019 № ПР-134-1

г. Казань

**Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә дәүләт телләре турындагы законнарны гамәлгә ашыру турында**

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Телләр турындагы законнарын гамәлгә ашыру советы рәисе урынбасары В.Г.Шәйхразиевның Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә дәүләт телләре турындагы законнарны гамәлгә ашыру хакында мәгълүматын тыңлап һәм тикшереп, “Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре советы” (алга таба – Совет) Ассоциациясе президиумы **карар бирде:**

1. Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Телләр турындагы законнарын гамәлгә ашыру советы рәисе урынбасары В.Г.Шәйхразиевның Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә дәүләт телләре турындагы законнарны гамәлгә ашыру хакында мәгълүматын игътибарга алырга.
2. Муниципаль берәмлекләр башлыкларына тәкъдим итәргә:

республика дәүләт телләрен өстенлекле куллану җитмәү өлешендә Татарстан Республикасы дәүләт телләре турындагы законнарга мониторинг үткәрергә һәм, алар булса, закон бозуларны бетерергә;

түбән күрсәткечләр ирешелгәндә, аларны үтәү буенча эшне оештырырга.

3. Әлеге карарны үтәүгә контрольне Советның башкарма секретаре А.Г.Барышевка йөкләргә.

**Рәис** **Ә.С. Гобәйдуллин**